# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

2020 елның 27 феврале № 269

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советының 2017 елның 17 июлендәге 116 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында «Интернет» челтәрендә урнаштырыла торган мәгълүмат исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге № 8-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2015елның 16 нчы январындагы № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Бишнә авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советының 2017 елның 17 июлендәге 116 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының «Интернет» челтәрендәге эшчәнлеге турында мәгълүматлар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. IV бүлегендә 26 пунктны төшереп калдырырга: «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында статистик мәгълүмат.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составында Зеленодольск муниципаль районы информацион сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» информацион телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда урнаштырырга: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт ( авыл мәдәният йорты бинасы).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Бишнә авыл җирлеге башлыгына йөкләнә.

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы, Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**